РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«24» октябрь 2023г.

№ 166

Теләче муниципаль районында 2024 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карары нигезендә, ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге»нең 2023 елның 11 сентябрендәге 01/1430 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга расларга:

- Теләче муниципаль районында 2023 елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны, кушымта нигезендә;

- балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнарны төзәтмәләр коэффициентын 0,65 күләмендә.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чор дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«24» 10 2023 № 166
карары белән расланган

Теләче муниципаль районында елга балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм мәдәният юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру өчен норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу урыны | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | Авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | Авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | Авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | Авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экология-биология | Авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | Авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | Авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисади | Авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый-фәнни | Авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |